КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 12 ноябрь г.Казань № б-2289

Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар арасында җинаятьләрне һәм хокук бозуларны кисәтү һәм яшүсмерләр мохитен криминалсызландыру максатларында:

1. Бу боерыкка теркәлгән 2025 елга кадәр балигъ булмаганнар арасында җинаятьләрне һәм хокук бозуларны кисәтү һәм яшүсмерләр мохитен криминалсызландыру өлкәсендә хезмәттәшлек итүнең комплекслы ведомствоара планын (алга таба – План) расларга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына түбәнәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына – гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

План чараларының үтәлешен тәэмин итүне;

ярты елга бер тапкыр, хисап чорыннан соң килә торган айның 10 ысына кадәр, Планны тормышка ашыру барышы турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына кертүне.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына бу боерыкның 2 пункты нигезендә алынган мәгълүматны гомумиләштерергә һәм ярты елга бер тапкыр, хисап чорыннан соң килә торган айның 30 ына кадәр, аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетларына балигъ булмаганнар арасында җинаятьләрне һәм хокук бозуларны кисәтү һәм яшүсмерләр мохитен криминалсызландыру буенча муниципаль планнар эшләүне һәм аларны раслауны тәкъдим итәргә.

5. План чараларын финанслау тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында План чараларын үтәүче Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына карала торган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 12 ноябрь, б-2289 нчы
боерыгы белән расланды

# 2025 елга кадәр балигъ булмаганнар арасында җинаятьләрне һәм хокук бозуларны кисәтү һәм яшүсмерләр мохитен криминалсызландыру өлкәсендә хезмәттәшлек итүнең комплекслы ведомствоара планы

| Т/с | Чараның исеме | Үтәү срогы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, сукбайлыгын, хокук бозуларын һәм җинаятьләрен һәм аларга карата мөнәсәбәтләрен профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар | | | |
| 1. | Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеге, сукбайлыгы, наркоманиясе, токсикоманиясе, алкоголизмы һәм хокук бозулары торышы турындагы статистик һәм мәгълүмат бирү характерындагы аналитик материалларны Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенә кертү һәм комиссия утырышларында санап үтелгән мәсьәләләрне карап тикшерү | даими | Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре (килешү буенча) |
| 2. | Социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турында Татарстан Республикасы бердәм мәгълүматлар банкын формалаштыру мәсьәләсе буенча эшче төркем утырышларын оештыру һәм үткәрү | квартал саен | ТР Хезмәт министрлыгы[1], ТР буенча ЭЭМ (килешү буенча), ТР ЯЭМ, ТР МһФМ, ТР ССМ, ТР ММ, ҖҮФХ ТР буенча идарәсе (килешү буенча), ББЭһАХЯРК |
| 3. | Татарстан Республикасы территориясендә Яшүсмер» ведомствоара профилактика операциясен әзерләү һәм үткәрү | ел саен | ББЭһАХЯРК, ТР ЯЭМ, ТР МһФМ, ТР Хезмәт министрлыгы, ТР буенча ЭЭМ (килешү буенча), ББЭһАХЯ буенча муниципаль комиссияләр (килешү буенча), ТР ДОСААФы (килешү буенча) |

[1] Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге – 4 нче биттә.

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 4. | Социаль куркыныч хәлдә булган һәм тормыш авыр хәлдә калган һәм социаль ярдәмгә мохтаҗ балигъ булмаганнарны ачыклау | даими | Җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 5. | Социаль куркыныч хәлдә булган балаларны һәм гаиләләрне, шулай ук балалар белән рәхимсез мөгамәләгә кылучы затларны ачыклау, аларга «СКХ» МС ярдәмендә сигнал карталарын җибәрү | даими | Опека һәм попечительлек муниципаль органнары (килешү буенча), сәламәтлек саклау идарәләре (килешү буенча), мәгариф идарәләре (килешү буенча), яшьләр эшләре органнары (килешү буенча), спорт органнары (килешү буенча), мәдәният учреждениеләре (килешү буенча), эчке эшләр органнарының территориаль бүлекчәләре (килешү буенча), ведомство буйсынуындагы социаль яклау органнары (килешү буенча), җинаять-утәтү инспекцияләре (килешү буенча) |
| 6. | Бердәм балалар ышаныч телефоны эшчәнлеген тәэмин итү | даими | ТР ЯЭМ, ТР Хезмәт министрлыгы, ТР ССМ, ТР МһФМ, «Росток» ППТһКҮ ДАМУ |
| 7. | Балалар белән рәхимсез мөгамәлә итүгә каршы тору буенча төбәк мәгълүмат кампаниясен үткәрү | даими | «ТАТМЕДИА» АҖ, җирле үзидарә органнары (килешү буенча), ТР Хезмәт министрлыгы, ТР МһФМ, ТР буенча ЭЭМ (килешү буенча), ТР ССМ |
| 8. | Зурлар ягыннан балаларга карата җинаять кылу буенча ачыкланган барлык фактлар турында территориаль эчке эшләр органнарына мәгълүмат бирү | даими | Опека һәм попечительлек муниципаль органнары (килешү буенча), ТР Хезмәт министрлыгы, ТР МһФМ, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Татарстан Республикасы мәгариф оешмалары (килешү буенча), ББЭһАХЯ буенча муниципаль комиссияләр (килешү буенча), ТР ССМ, Татарстан Республикасы медицина оешмалары (килешү буенча) |
| 9. | Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, хокук бозуларын һәм суицидларын профилактикалауга, яшүсмерләр мохитендә деструктив күренешләрне кисәтүгә, балалар һәм яшүсмерләрнең хокукларын һәм | даими | «ТАТМЕДИА» АҖ, ТР ЯЭМ, ТР МһФМ, ТР Хезмәт министрлыгы, ТР ССМ, ТР буенча ЭЭМ (килешү буенча), РФ ТК ТР буенча тикшерү идарәсе (килешү буенча), ТР буенча |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | законлы мәнфәгатьләрен яклауга юнәлдерелгән чараларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту | | Роскомкүзәтчелек (килешү буенча), «Доверие» ХСХККҮ» ДАСХКУ, ТР ММ, СПФХ ТР буенча идарәсе (килешү буенча), опека һәм попечительлек органнары (килешү буенча), Татарстан Республикасы буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил |
| 10. | Татарстан Республикасының барлык муниципаль районнарында социаль участокларда җаваплы ата-ана мәктәпләре эшен оештыру | даими | ТР Хезмәт министрлыгы |
| 11. | Гражданнарны ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү яки аларга чикләүләр кертү очракларын профилактикалау максатларында, балигъ булмаган балалары булган ата-аналарны исерткеч эчемлекләргә һәм наркотикларга бәйлелектән дәвалауны оештыру | даими | ТР ССМ |
| 12. | Балигъ булмаган балалары, социаль куркыныч хәлдә булган, муниципаль берәмлекләрдә ведомствоара исәптә торган ата-аналарны исерткеч эчемлекләргә һәм наркотикларга бәйлелектән дәвалауга җибәрүдә булышлык күрсәтү | даими | Җирле үзидарә органнары (килешү буенча), ТР ССМ, ТР Хезмәт министрлыгы |
| 13. | Татарстан Республикасы мәгариф оешмалары базасында мәктәп медиация (кабул итеп килешү) хезмәтләре челтәрен үстерү һәм камилләштерү | даими | ТР МһФМ, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары (килешү буенча), мәгариф оешмалары (килешү буенча), ББЭһАХЯ буенча муниципаль комиссияләр (килешү буенча) |
| 14. | Гаиләләрне тикшерү (бергәләп баруларны оештыру) һәм аларга «Татарстан Республикасында социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнарны һәм аларның гаиләләрен исәпкә алу һәм мониторинглау» мәгълүмат системасы ярдәмендә сигнал картасын җибәрү | даими | Җирле үзидарә органнары (килешү буенча), ТР Хезмәт министрлыгы, ТР МһФМ, ТР буенча ЭЭМ (килешү буенча), ТР ССМ |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 15. | Балигъ булмаганнарның һәм яшьләрнең укудан тыш вакытта альтернатив ял итү эшчәнлеген, ялын һәм аларны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру | даими | Җирле үзидарә органнары (килешү буенча), ТР МһФМ, ТР ЯЭМ, ТР СМ, ТР ММ, ТР Хезмәт министрлыгы |
| 16. | Профилактик исәптә торучы яшүсмерләрне өстенлекле рәвештә вакытлы һәм даими эшкә урнаштыруны һәм эш белән тәэмин итүне оештыру | даими | ТР Хезмәт министрлыгы, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 17. | Социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрне тернәкләндерү буенча индивидуаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру | даими | Җирле үзидарә органнары (килешү буенча), ТР Хезмәт министрлыгы, ТР МһФМ, ТР буенча ЭЭМ (килешү буенча), ТР ССМ, ТР ЯЭМ, ТР СМ, ҖҮФХ ТР буенча идарәсе (килешү буенча) |
| 18. | Иректән мәхрүм итүгә бәйле булмаган җәза чараларына хөкем ителгән балигъ булмаганнарның яшәү рәвешен өйрәнү һәм торак-көнкүреш шартларын тикшерү буенча уртак чаралар үткәрү | квартал саен | ҖҮФХ ТР буенча идарәсе (килешү буенча), ТР буенча ЭЭМ (килешү буенча) |
| 19. | Җәйге чорда социаль куркыныч хәлдә булган һәм профилактика системасы органнарында һәм учреждениеләрендә профилактик исәптә торучы балигъ булмаганнарны савыктыруны һәм эш белән тәэмин итүне оештыру | даими | Җирле үзидарә органнары (килешү буенча), ТР ЯЭМ, ТР МһФМ, ТР Хезмәт министрлыгы, ББЭһАХЯ буенча муниципаль комиссияләр (килешү буенча), ТР буенча ЭЭМ (килешү буенча), ТР ДОСААФы (килешү буенча) |
| 20. | Балигъ булмаганнар һәм аларның ата-аналары арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау эшен камилләштерү | даими | ТР ССМ, ТР ЯЭМ, ТР СМ, ТР ММ, ТР МһФМ |
| 21. | Законда каралган йогынты чараларын кабул итеп, балигъ булмаган хокук бозучыларны, шулай ук балигъ булмаганнарны хокукка каршы гамәлләр кылуга җәлеп итүче затларны ачыклау буенча максатчан профилактик чаралар, рейдлар үткәрүне оештыру | даими | ТР буенча ЭЭМ (килешү буенча) |

Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:

«Росток» ППТһКҮ ДАМУ – «Росток» психологик-педагогик тернәкләндерү һәм коррекцияләү үзәге дәүләт автоном мәгариф учреждениесе;

«Доверие» ХСХККҮ» ДАСХКУ – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Доверие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе;

ТР ДОСААФы – «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле җәмгыяте» төбәк иҗтимагый-дәүләт оешмасы;

«СКХ» МС – Татарстан Республикасында социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны исәпкә алу һәм мониторинглау» мәгълүмат системасы;

ТР буенча ЭЭМ – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы;

ТР ЯЭМ – Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы;

ТР ССМ – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрлыгы;

ТР ММ – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы;

ТР СМ – Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы;

ББЭһАХЯ буенча муниципаль комиссияләр – балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр;

ТР МһФМ – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

ТР Хезмәт министрлыгы – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

ББЭһАХЯРК – Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе;

ТР буенча Роскомкүзәтчелек – Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә федераль күзәтчелек итү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе;

ММЧ – массакүләм мәгълүмат чаралары;

РФ ТК ТР буенча тикшерү идарәсе – Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе;

СПФХ ТР буенча идарәсе – Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе;

ҖҮФХ ТР буенча идарәсе – Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе.